КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 октябрь г.Казань № 834

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә ярдәм турында» 2025 ел, 14 июль, 515 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә ярдәм турында» 2025 ел, 14 июль, 515 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен расларга.»

2 пунктның өченче абзацында «бирү турында карар кабул итү» сүзләрен «гамәлгә ашыру» сүзе белән алыштыру;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибендә:

2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык, мәдәният хезмәткәре һәм мәдәният оешмасы арасында бер тапкыр бирелә торган компенсация түләү турында өч яклы килешү төзегәннәр өчен (алга таба – килешү).»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Министрлык бер тапкыр бирелә торган компенсация түләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 10 эш көне эчендә килешүнең өч нөсхәсен имзалый һәм аларны имзалау өчен мәдәният оешмасына җибәрә.

Мәдәният оешмасы килешүнең өч нөсхәсен алган көннән башлап өч эш көне эчендә аларны мәдәният хезмәткәре һәм мәдәният оешмасы җитәкчесе тарафыннан имзалауны тәэмин итә.

Шартнамәгә кул куелганнан соң мәдәният оешмасы бер нөсхәсен мәдәният хезмәткәренә, бер нөсхәсен кул куелганннан соң өч эш көне эчендә Министрлыкка кире кайтара.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве мәдәният хезмәткәренә Министрлык тарафыннан, агымдагы елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, гаризада күрсәтелгән Россия кредит оешмасында ачылган мәдәният хезмәткәре счетына акча күчерү юлы белән башкарыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин